ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1837**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән, шул исәптән ике тапкыр түләүсез тукылануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 15 июнендәге 1766 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2012 елның 29 декабрендәге«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7, $7^1$, $7^2$ өлешләре нигезендә, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Туклану компенсациясе бәясен исәпләү турында» 2023 елның 09 февралендәге АБ-562/07 номерлы хатына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән, шул исәптән ике тапкыр түләүсез тукылануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 15 июнендәге 1766 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

1.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән, шул исәптән ике тапкыр түләүсез тукылануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген тәэмин итү тәртибен түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

«1.9. Туклану чикләүләре белән бәйле авырулары булмаган һәм дәвалау һәм диетик тукылануга мохтаҗ булмаган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен , уртача тәүлеклек наборлар «Халыкның җәмәгать тукылануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар-

эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 27 октябрендәге карары нигезендә кабул ителә торган нормалардан чыгып һәм мәгариф оешмасында гамәлгә ашырыла торган менюга нигезләнеп исәпләнә.

Туклану чикләүләре белән бәйле авырулары булган һәм дәвалау һәм диетик туклануга мохтаҗ булмаган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен , уртача тәүлеклек наборлар туклану нормаларыннан һәм конкрет нозологияне һәм медицина оешмасының белем алучы өчен билгеләмәләрен (киңәшләрен) исәпкә алып төзелгән менюдан чыгып исәпләнә. Туклану бәясен исәпләгәндә Туклану бәясен исәпләгәндә 2019 елның 30 декабрендәге Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан расланган «Шикәр диабеты һәм туклануда чикләүләр белән бергә йөрүче башка авырулардан интегүче балаларның туклануын оештыру үзенчәлекләре (мәгариф һәм сәламәтләндерү оешмаларында)» МР 2.4.0162-19 методик тәкъдимнәре кулланылырга мөмкин.».

1.3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген тәэмин итү тәртибе 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. 2022-2023 уку елында өйдә белем алучыларны түләүсез тукландыру турында карар гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан гариза нигезендә, әлеге Тәртип расланган көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә.»

1.4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өйдә белем алу оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеген тәэмин итү тәртибенең 2.16 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022-2023 уку елы өчен акчалата компенсация 2023 елның 31 августына кадәр түләнә.»

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин